ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»

«ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

09.09.2026 г.Лениногорск № 613

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2024 елның 9 октябрендәге 1295 номерлы карары белән расланган Муниципаль мөлкәтне арендага, торглар үткәрмичә түләүсез файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш кертү турында

«Россия Федерациясендә туристлык эшчәнлеге нигезләре турында» Федераль законның 4 һәм 19.5 статьяларына һәм «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» Федераль законның 15 һәм 15.1 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 29 декабрендәге 552-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2024 елның 9 октябрендәге 1295 номерлы карары белән расланган Муниципаль мөлкәтне арендага, торглар үткәрмичә түләүсез файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

2.14.2 пунктта:

1 пунктчада «башка оешмалар),» сүзләреннән соң «туристлык эшчәнлеге турында Россия Федерациясе законнары нигезендә классификацияләнергә тиешле туристлык индустриясе объектларына («Кунак йортлары хезмәтләрен күрсәтү буенча эксперимент үткәрү турында» 2025 елның 7 июнендәге 127-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә урнаштыру чараларына караган объектлардан һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән тыш) (алга таба - туристлык индустриясе объектлары) сүзләре белән тулыландырырга,»;

3 пунктчада «транспорт инфраструктурасы,» сүзләреннән соң «туристлык индустриясе объектлары,»сүзләре белән тулыландырырга;

4 пунктны «, туристлык индустриясе объектлары» сүзләре белән тулыландырырга;

5 пунктта «транспорт инфраструктурасы» сүзләреннән соң «туристлык индустриясе объектлары» сүзләре белән тулыландырырга;

7 нче пунктта «транспорт инфраструктурасы» сүзләреннән соң «турист индустриясе объектлары» сүзләре белән тулыландырырга.

2.Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

3.Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының рәсми Интернет-сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче И.Г.Шәмәрданов

Л.М. Галимова
5-44-72